Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге Советы Карары

«30» октябрь 2020 ел № 7

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 113 номерлы «Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендә кабул ителгән 113 номерлы «җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Билгеләү:

4.1. Календарь елы салым чоры дип таныла.

4.2. Салым түләүчеләр-оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы таныла.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб – адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев

СОВЕТ КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1610000733